КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь

г.Казань

№ 1121

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын чыгару белән бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1006 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын чыгару белән бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 30 декабрь, 1006 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы редакциясе» автоном коммерциячел булмаган оешмага Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын чыгару белән бәйле чыгымнарын каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә, «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары җыентыкларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнары җыентыгы» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет чаралары алучысы буларак билгеләнгән тәртиптә Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм мәгълүмат чаралары агентлыгына (алга таба – вәкаләтле орган) бирелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында бирелә.»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Оешмага бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + З_4 + З_5 + З_6 + З_7 + З_8 + З_9,$$

монда:

С – оешмага бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$ – штаттагы һәм штаттан тыш хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүгә акча тоту;

$З_2$ – бюджеттан тыш фондларга иминият кертемнәрен, җитештерүдә бәхетсез очраклардан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминият буенча кертемнәрне, дәүләт пошлиналарын, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бүтән мәҗбүри күчерүләрне һәм түләүләрне түләүгә акча тоту;

$З_3$ – типография һәм полиграфия хезмәтләре күрсәтүне, журналны, шул исәптән мәҗбүри нөсхәсен, алып килеп бирү (транспортлау) һәм тарату чыгымнарын түләүгә акча тоту;

$З_4$ – бүлмәләрне арендалауга, техник чаралар сатып алуга, коммуналь хезмәтләргә түләүгә, элемтә хезмәтләренә түләүгә, программа белән тәэмин итү (бухгалтер программалары, антивирус программалар, электрон хисаплылык)

чыгымнарын түләүгә, белешмә-мәгълүмат базаларын яңартуга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдалануга акча тоту;

$З_5$ – интернет-сайтны карап тоту һәм аны алып бару буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә акча тоту;

$З_6$ – канцелярия һәм чыгым материалларын, инвентарь, офис техникасын сатып алуга, аңа хезмәт күрсәтүгә (ремонт) акча тоту;

$З_7$ – авторлык һәм эргәдәш хокуклар буенча түләүләргә акча тоту, архив материалларын, компьютер графикасын файдалануга чыгымнардан тыш;

$З_8$ – редакция чыгымнарына акча тоту;

$З_9$ – банк хезмәтләре күрсәтүгә акча тоту.»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырылган айга кадәр булган айның беренче көненә оешма түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

оешманың салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы юк;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында түгел;

агымдагы финанс елында әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмаганнар.»;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ һәм $3^2$ пунктлар өстәргә:

«$3^1$. Субсидия алу өчен оешма вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыра:

вәкаләтле орган билгеләгән форма буенча, Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарның исәп-хисапларын һәм нигезләүләрне теркәп, субсидия алуга заявканы;

субсидия алуга заявкага имза куйган затның вәкаләтләрен раслый торган документларны;

оешма җитәкчесе (бүтән вәкаләтле зат) имзасы һәм мөһере белән таныкланган гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

субсидия күчерү өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмасы учреждениесендә ачылган исәп-хисап счетының реквизитлары күрсәтелгән, оешма җитәкчесе (бүтән вәкаләтле зат) һәм баш хисапчысы имза куйган белешмәне;

оешманың штат җәдвалын;

узган финанс елына бухгалтер балансын;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә оешманың туры килүен раслый торган, оешма җитәкчесе (бүтән вәкаләтле зат) һәм баш хисапчысы имза куйган, оешма мөһере белән беркетелгән белешмәне;

Татарстан Республикасы законнары җыентыгын чыгару белән бәйле чыгымнарны раслый торган документлар күчермәләрен: шартнамәләр, түләү

йөкләмәләре, накладнойлар, счетлар, счет-фактуралар, башкарылган эшләр актлары, вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан таныкланган исәп-хисап кәгазьләре (булганда).

Документлар кәгазьдә һәм электрон мәгълүмат йөртү җайланмаларында тапшырыла ала.

Оешма үз башлангычы белән вәкаләтле органга оешманы салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен тапшырырга хокуклы. Әлеге документ күчермәсе оешма башлангычы белән тапшырылмаган очракта вәкаләтле орган аны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органыннан соратып ала.

$3^2$. Вәкаләтле орган субсидия алуга заявканы һәм оешма тапшырган документларны журналга терки, ул кергән көнендә шнурланган, сан сугылган һәм вәкаләтле органның мөһере белән беркетелгән булырга тиеш.

Вәкаләтле орган ике эш көне эчендә субсидия бирү турында заявканы һәм аңарга теркәлгән документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында карар кабул итә.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләр:

оешма тапшырган документларның әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

оешма тапшырган мәгълүматның дөрес булмавы.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта вәкаләтле орган әлеге карар кабул ителгән көннән соң ике эш көне эчендә субсидия алуга заявканы һәм тапшырылган документларны, кабул ителгән карарның нигезле булуы күрсәтелгән хәбәрнамә белән кире кайтара.»;

5 пунктны төшереп калдырырга;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субсидия бирү килешү нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк формага ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Килешү субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә төзелә.

Килешүдә күздә тотыла:

субсидия бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе;

аларны кайтару өчен субсидия бирелә торган чыгымнар исемлеге;

субсидия күләме һәм аны алу чыганагы;

субсидия күчерү вакытлары (вакыттан вакытка кабатлануы);

әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен оешма үтәүне вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан мәҗбүри тикшерү турында нигезләмә;

әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен оешма үтәүне вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тикшерүне гамәлгә ашыруга оешманың ризалыгы;

алынган акчага чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш;

субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозган өчен субсидия алучының җаваплылыгы;

субсидия акчасы керү һәм тотуның аерым бухгалтер исәбен алып бару турында таләп;

вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр йомгаклары буенча әлеге Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен бозу фактлары билгеләнгән очракта субсидияне кире кайтару тәртибе;

килешүдә каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен агымдагы финанс елында оешма тарафыннан кире кайтару тәртибе;

вәкаләтле орган билгеләгән субсидияне файдалану турында хисап бирү вакытлары һәм формалары.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән һәм оешма субсидиядән файдалану турында хисап тапшырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә, алга таба – ай саен оешма субсидиядән файдалану турында хисап тапшырган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә вәкаләтле орган субсидияне оешманың Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмасы учреждениесендә ачылган исәп-хисап счетына күчерә.

Оешма субсидия күчерү өчен билгеләнгән түләү реквизитлары үзгәрү турында үзгәреш көненнән соң биш эш көне эчендә, язмача мәгълүмат кәгазе җибәрү юлы белән вәкаләтле органга хәбәр итә.»;

8 пунктта «килешүдә каралган формага һәм тәртипкә ярашлы рәвештә» сүзләрен «килешү белән каралган вакытларда һәм формада» сүзләренә алмаштырырга;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Түбәндәге очракларда вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә субсидия Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш:

субсидияне максатчан билгеләнешендә файдаланмау;

субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру;

субсидия бирү шартларны бозу;

субсидиядән файдалану турында хисапны вакытында тапшырмау.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Әлеге Тәртипнең 9 һәм 10 пунктларында күрсәтелгән субсидияне яки субсидиянең калган өлешен кире кайтару вакытлары бозылганда, вәкаләтле орган субсидияне яки субсидиянең калган өлешен кире кайтару вакытлары узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча чаралар күрә.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы оешма тарафыннан субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүен тикшерүне законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин